РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.06.2023 Кукмара ш. №357

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының 2023 – 2025 елларга халык сәламәтлеген яхшырту һәм үлемне киметү» муниципаль программасын раслау турында

«2025 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 01 июлендәге 461 номерлы карарын үтәү йөзеннән **карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының 2023 – 2025 елларга халык сәламәтлеген яхшырту һәм үлемне киметү» муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.
2. Кукмара муниципаль берәмлегенең Финанс-бюджет палатасына ел саен чираттагы финанс елына район бюджетын формалаштырганда Программа чараларын гамәлгә ашыруга акчаны карарга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Социаль мәсьәләләр буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.М. Әхмәтшинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**